**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

11.02.2022 № 91

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында» боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында» 2011 елның 14 апрелендәге 172 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 28 апрелендәге 181 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 24 июлендәге ПУ-617 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 13 сентябрендәге 444 номерлы, 2013 елның 6 ноябрендәге 537 номерлы, 2014 елның 5 августындагы 469 номерлы, 2014 елның 10 декабрендәге 697 номерлы, 2015 елның 15 августындагы 462 номерлы, 2016 елның 16 маендагы 294 номерлы, 2016 елның 22 декабрендәге 743 номерлы, 2017 елның 28 апрелендәге 258 номерлы, 2017 елның 7 июлендәге 427 һәм 2017 елның 11 декабрендәге 719 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәдә:

6 пунктның «а» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

12 пунктның «б» пунктчасының икенче абзацында «аларга билгеләп куелганда гражданнар һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия составын әлеге боерыкка кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның « 11 » февралендәге
91 номерлы боерыгына
кушымта

**Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия**
**составы**

| | |
|---|---|
| Гарипов Илнур Мәхмүт улы | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы, Комиссия рәисе |
| Белов Александр Николаевич | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты җитәкчесе, Комиссия рәисе урынбасары |
| Зиннәтуллина Лилия Рифхәт кызы | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментының кадрлар бүлеге мөдире, Комиссия секретаре |
| Бәдретдинов Марс Сарыйм улы | Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе башлыгы |
| Глухова Лариса Юрьевна | Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы |
| Павлова Мария Андреевна | Татарстан Республикасы Президентының Эксперт департаменты Икътисадый анализ идарәсе башлыгы урынбасары, Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының башлангыч һөнәр берлеге оешмасы рәисе |
| Привалов Игорь Анатольевич | Казан (Идел буе) федераль университетының Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Терентьева Ирина Васильевна | Казан (Идел буе) федераль университеты проректоры референт-ярдәмчесе, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Ветераннар советы рәисе (килешү буенча) |

---